ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2025 п.г.т. Алексеевское № 511

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 11.09.2017 ел, № 345 «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.09.2025 ел, № 763 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.08.2017 ел, № 569 карары белән расланган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә, Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү Методикасына үзгәреш кертү турында» карарына туры китереп

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 11.09.2017 ел, № 345 «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы

Нигезләмәнең II бүлегенең, «хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә:

« Таблица 1

| № т/б | Хезмәткәрләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Учреждение җитәкчесе | 33 345,00 |
| 2 | Оператив дежур | 25 650,00 |

».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Е. М. Мифтаховага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**